СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2020 г. Заинск № 181

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2015 елның 29 апрелендәге 208 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советына депутатлар сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын төгәлләштерү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашуга хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25 статьясы нигезендә, Зәй шәһәре территориясенең алга таба үсүенә, яңа урамнар барлыкка килүгә һәм яңа йортларны файдалануга кертүгә бәйле рәвештә, округларның расланган чикләре чикләрендә бермандатлы сайлау округларының гамәлдәге схемасын төгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Бермандатлы сайлау округларының тасвирламасына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2015 елның 29 апрелендәге 208 номерлы карарына кушымта) түбәндәгеләрне кертеп, төгәлләштерергә:

1.1. 3 номерлы Воздвиженка бермандатлы сайлау округына: Горбунов урамын; Гагарин урамының 1-48 йортларын; Тукай урамының 39/2 йортын.

1.2. 5 номерлы Никифоров бермандатлы сайлау округына: Рәфыйков урамының 74 йортын.

1.3. 7 номерлы Төзүчеләр бермандатлы сайлау округына: Төзүчеләр урамының 9/2, 13 йортларын.

1.4. 8 номерлы Энергетиклар бермандатлы сайлау округына: Елга урамының 1 Г; Төзүчеләр урамының 8/1 йортын.

1.5. 9 номерлы Нефтьчеләр бермандатлы сайлау округына: Октябрь урамының 4/1, д.6/1; Төзүчеләр урамының.1, 4/1, 4/2, 6/2 йортларын.

1.6. 11 номерлы Май заводы бермандатлы сайлау округына: Казан урамының 12 йортын.

1.7. 15 номерлы Лицей бермандатлы сайлау округына: Җиңү проспектының 1/21Б йортын.

1.8. 16 номерлы Симашев бермандатлы сайлау округына: Девятаев урамын.

1.9. 20 номерлы Совхоз бермандатлы сайлау округына: Чәчәкле тыкрык урамын.

2. Бермандатлы сайлау округларының тасвирламасыннан (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2015 елның 29 апрелендәге 208 номерлы карарына кушымта) түбәндәгеләрне чыгарып, төгәлләштерергә:

2.1. 2 номерлы Интернат бермандатлы сайлау округыннан: Никифоров урамының 66 йортын.

2.2. 4 номерлы Гимназия бермандатлы сайлау округыннан: Ленин урамының 30 йортын.

2.3. 18 номерлы Урман хуҗалыгы бермандатлы сайлау округыннан: Мичурин тыкрыгы урамын.

2.4. 20 номерлы Совхоз бермандатлы сайлау округыннан: Ирек тыкрыгы; Чокырлы тыкрыгы урамнарын.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үз өстемдә калдырам.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**